**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«27» июнь 2024 ел** **№ 237**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль хезмәте турында Нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 18 июнендәге 219 номерлы Нурлат муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 - ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594 номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2019 елның 18 июнендәге 219 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында"гы нигезләмәгә (2019 елның 10 октябрендәге 240 номерлы, 2020 елның 19 августындагы 301 номерлы, 2020 елның 16октябрендәге 19 номерлы, 2021 елның 03 декабрендәге 88 номерлы, 2023 елның 09 августындагы 184 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 7нче бүлектә

7.4нче пунктында:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны»;»;

7 нче бүлекнең 7.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел, № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы нигезендә граждан тарафыннан муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.»;

9) 18нче бүлектә:

18.1 пунктында:

түбәндәге эчтәлектәге 12нче пункт белән тулыландырырга:

«12) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә,

яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш(алга таба- анкетада булган мәгълүматлар).»;

18.3 пунктында:

8нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) ул үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар бирмәүче, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә);»;

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Советының Законлылык һәм хокук тәртибен саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль
районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев